ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.03.2019 № 287

2019 нчы елга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла торган хокук бозуларны профилактикалау программасын раслау турында

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 8.2 статьясындагы 1 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 нчы елга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла торган хокук бозуларны профилактикалау программасын расларга.
2. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнарына һәм вазыйфаи затларына, үз компетенциясе чикләрендә, әлеге карарның 1 пункты белән расланган хокук бозуларны профилактикалау программасын үтәүне тәэмин итәргә.
3. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының торакны исәпкә алу һәм бүлү бүлеге башлыгына ел саен 01 нче декабрьгә кадәр алдагы елга хокук бозуларны профилактикалау программасын эшләүне тәэмин итәргә.
4. Кабул ителгән карарны рәсми рәвештә масса - күләм мәгълүмат чараларында бастырырга .
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.С. Хәйруллин